МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

28.04.2026 № 106

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 07.09.2023 № 228 «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә салынган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының Комиссиясе турында» боерыгына үзгәрешләр кертү турында**

2010 ел 25 нче август № УП-569 «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, боерык бирәм:

1. 07.09.2023 № 228 Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы (алда – Татарстан Республикасы ГТХМ) боерыгы белән (04.07.2024 № 169, 10.03.2025 № 46, 09.06.2025 № 117, 27.02.2026 № 50 Татарстан Республикасы ГТХМ боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә салынган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының Комиссиясе турында Нигезләмәгә алдагы үзгәрешләрне кертергә:

6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Комиссия Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән төзелә. Бирегәге боерык тарафыннан Комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, Комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре билгеләп куела һәм Комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

7 нче пунктның "а" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы ГТХМ министры урынбасары (Комиссия рәисе), Татарстан Республикасы ГТХМ дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче зат (Комиссия рәисе урынбасары), Татарстан Республикасы ГТХМ кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (Комиссия секретаре), Татарстан Республикасы ГТХМ дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәләрдән, юридик (хокукый) бүлектән, башка бүлекчәләрдән министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алда – министр) билгели торган дәүләт хезмәткәрләре;»;

9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Әлеге Нигезләмәнең 7 нче пунктының «б» һәм «в» пунктчаларында һәм 8 нче пунктында күрсәтелгән затлар, Татарстан Республикасы Рәисенең коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе, фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары, Татарстан Республикасы ГТХМ каршында оештырылган Иҗтимагый совет, Татарстан Республикасы ГТХМда төзелгән ветераннарның иҗтимагый оешмасы белән килешү буенча Комиссия составына билгеләнгән тәртиптә кертеләләр.»;

15 нче пунктның «а» подпунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы Нигезләмәдә (Татарстан Республикасы Президентының 2009 ел 30 нчы декабрь № УП-702 Указы белән расланган) каралган дәүләт хезмәткәренә дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр бирү турында;»;

28 нче пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы Нигезләмәдә (Татарстан Республикасы Президентының 2009 ел 30 нчы декабрь № УП-702 Указы белән расланган) каралган дәүләт хезмәткәре тапшырган белешмәләрнең дөрес һәм тулы булуын билгеләргә;».

2. 2. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасы ГТХМ структур бүлекчәләре җитәкчеләренә, министр урынбасарларына һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә.

Министр вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы п/п А.Н. Орлов